**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советы Карары**

18 октябрь 2018 ел № 75

2017 елның 13 сентябрендәге ""Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында"гы Нигезләмә турында"гы 47 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законга үзгәрешләр кертү сәбәпле, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советы, гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. 2017 елның 13 сентябрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советының 47 номерлы карары белән расланган "Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында"гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 11 маддәнең 1 өлешендәге 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә катнашудан тыш, съезд (конференцияләрдән тыш) яки башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләре), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш; гамәлгә куючы (акционер) булган муниципаль берәмлек идарә һәм ревизия

комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү, муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә; федераль законнарда каралган башка очракларда, шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;».

2. Депутат 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы көрәш турында"гы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында"гы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы "Аерым категорияләрдәге затларның счетларын (кертемнәрен) ачуны һәм саклауны, чит ил банкларында акча чараларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклауны, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында"гы Федераль закон тарафыннан билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә (соблюдать), вазыйфаларны үтәргә (исполнять) тиеш"."

2. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Варварино авылы, Ленин урамы, 32 йорт,

- Көрәле авылы, Үзәк урам, 2а йорты,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Варварино авыл җирлеге Башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Варварино авыл җирлеге Советы**
**рәисе Р. Т. Нотфуллин**